# ӘНИЕМ – КОЯШЫМ

Ул елмайганда гөлләр уяна,
Ул булганда җирдә бәйрәм, тантана
Ул эндәшкәндә былбыллар тын
Кояштай талпынам аның янына.

*Кушымта:*
Күңелем түрендә бер кояш балкый,
Иртә-кич балкый, беркайчан батмый.
Ул минем әнием, сүнмәс җан җылым,
Якты йолдызым, канатла җырым!

Бишек җырлары үстерде мине,
Әни куллары йомшак та инде!..
Әйткән сүзләре канатлы дога,
Дәшә ул мине иң изге юлга.